Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!


ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ИЮНЬ * 2022 * КАЗАН

6



Александр ГАЛИЧ

ДӘШМИ КАЛУ, КАТЫЙЛЬЛЕККӘ БАРУ...

Берни кырмый, тик тә тормый
Бюджеттагы кайбер оешма...
Сорыкортлар кебек корта,
Миллилекне тормышта.
Алмаз ХӘМЗИН

Өлкәннәр чутында без күптән,
Балачак еракта, ул үткән...
Әкияти хәзинә эзләүгә
Омтылыш сүрелгән күзләрдә...

Эсселек бөркегән чүлләрдә,
Салкынлык саркыган җирләрдә,
Казыну – файдасыз мәрәкә,
Эндәшми калуда – бәрәкәт...

Дәшми кал, баерсың, этләшмә,
Йом күзең, эндәшмә, эндәшмә!
Тыңлама ярсыган йөрәкне
Акылга ышанма, кирәкми...

Чыдадык, гел телне тешләдек...
Карышмый, ә хуплап дәшмәдек,
Кемнәрдер шаулады, даулады...
Киттеләр бу җирдән аннары.

Юлы бер югалып калмауның,
Кәнәфи, түрәлек яулауның,
Дәшми түз, сүзләрдән күбенче,
Берзаман булырсың беренче!!

Ә инде ирешкәч максатка
Укшыта һәртөрле сафсата;
Мең тапкыр расланган, чын әгәр, –
Эндәшмәү – алтынга бәрабәр!..

Башкалар кычкырсын буылып,
Рәнҗештән, ачлыктан ачынып!
Үзгәләр дуласын, шашынып!..
Ә син тор бер читтә, кашынып...

Бик ансат үрелү калачка,
Бик җиңел әверелү палачка...
Ни кирәк тормыштан, шуны ал,
Дәшми кал, дәшми кал, дәшми кал...

ЧАМА

...Алдаш, якын дусларыңа ит хыянәт,
Фәхештә чик рәхәт уңда-сулда;
Килер кыямәт, тотарсың җавап...
Аңла, анысы бит әле аның соңра...

Рөстәм ЗАРИПОВ тәрҗемәсе.

Александр АЛЁШИН





ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Минем беркайчан да «Евровидение»гә исем китмәде. Тик шулай да ул җырлаучы кыланчыклар җыенында сирәк кенә булса да сәләтле шәхесләр очрап куйгалый иде. Ә соңгы шоу, минемчә, кайчандыр популяр булган конкурсның дәрәҗәсен бөтенләй юкка чыгарды. Оештыручылар, тамашачыларның биргән тавышларын әвеш-түеш китереп, җиңүне тавышсыз Украина рэперларына тапшырды. Бу инде «Евровидение»нең җыр бәйгесеннән сәяси конкурска әверелгәнен күрсәтте...

Е. СИТДЫЙКОВА

ЯШЕЛ ҮЗӘН

– Хәтта сәхнәгә Зеленский чыгып, рояльдә уйнап күрсәтсә дә, Украина барыбер җиңгән булыр иде... – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач.

Фәнзаман БАТТАЛ

АВЫЗЫН ЯПТЫ

Аннан урлап, моннан «сугып»
Яшәүче Михәйләгә,
Юлда туры килгәч, шулай,
Участковый бәйләнә:

– Күпме шулай көн итәрсең,
Урлашып, йә тузынып.
Кешелеккә файдаң кая?
Тәмам беттең узынып!..

Җавап өчен кесәсенә
Керәме соң Михәйлә?! –
Эшсез яшәп тел шомарткан –
Һәр сүзендә «мең хәйлә».

Әйтеп бирде ул елмаеп:
– Кү-үп минем сиңа файдам!
– Минем кебекләр булмаса,
Эш табар идең кайдан?!



Александр ШУЛЬПИНОВ

• • •

Командиры – солдатка:
– Син теге дөньяның барлыгына ышанасыңмы?
– Юк.
– Ышанмасаң, шул: бер ай элек, ял алып, бабаңны җирләп килгән идең. Менә шул бабаң сине күрше бүлмәдә көтеп утыра.



Сергей АНДРИАНОВ



Акчалар бакчасында

Акча ярдәмендә бөтен мәсьәләләрне дә хәл итеп буламы? Кызыклы сорау, әлбәттә. Акча эчендә йөзүчеләр яшьлекне дә, сәламәтлекне дә аңа сатып алып булмаганны яхшы беләләр. Ә кесәләрендә җил уйнап торганнар исә нәни генә запас барлыкка килүнең дә тормышны сизелерлек җиңеләйткәнен тоялар. Ләкин шул ук вакытта тегеләре дә, болары да акчаның мәсьәләләрне хәл итеп кенә калмый, ә яңа мәсьәләләр тудыра диган уртак фикердә торалар. Бигрәк тә ул ялган акча булса.

"Приколлар банкы" билетлары – чын акча кыяфәтендә ясалган купюралар нәкъ шундый проблема тудырдылар. Башта алар коллекционерлар өчен чыгарылган булсалар, бик тиз аның мөмкинлекләрен төрле мошенниклар да сизеп алды.

Чаллы кибетендә ир кеше сатучыга биш меңлек шундый ялган купюра сузган. Сдачасын алып, җиңел сулап куярга өлгергән генә, ләкин иртәрәк – ишек янында аны полицейскийлар эләктереп алган. "Прикол" остасына карата "мошенничество" статьясы буенча җинаять эше кузгатканнар.

Әгәр сәүдә хезмәткәрләре акча төрлелегендә нәрсәдер аңлый башлаганнар икән, өлкән яшьтәге кешеләр өчен бу катлаулы нәрсә. Күптән түгел шул ук Чаллыда 89 яшьлек әбекәйне үзенә тиеш 12 меңлек түләү белән шатландырганнар. Аның янына таныш булмаган хатын килеп, үзенең акча китерүе турында хәбәр иткән. Беркатлы карчык кунакны түргә чакырган, тегесе 15 мең сум биргән дә, сдача сораган. Кулына 3 мең сум кергән карак хатын шунда ук табанын ялтыраткан...

Алдауга килгәндә, моны чит кешеләр генә түгел, якын туганнар да бик оста эшли икән. Казанда яшәүче бер ханым шундый хәлгә дучар булган. Үзенең озак вакытлар фатирында җыеп барган өч мең долларның кәгазь кисәкләренә әйләнүен күргәч, ул полициягә мөрәҗәгать иткән. Тиздән каракның үзенең акча уеннары сөюче ире икәне ачыкланган.

Акчага кызыгу иң ышанычлы булып саналган банк хезмәткәрләрен дә читләтеп үтми икән. Казандагы "Открытие" банкы бүлекчәсе җитәкчесе шулай ук чын акчаны "прикол билетларына" алыштырып, юкка чыгарга тырышып караган. Банкирның аппетитлары киң колачлы булып чыккан – ревизия вакытында банкта 230 миллион сум чын акча җитмәгәне ачыкланган. Бу эшнең ахырын көтелмәгән дип әйтеп булмый – суд карары белән егеткә 6,5 елга ирек белән хушлашырга туры килгән...

Шунысы кызык: хәтта банкоматлар да ялган акчаны чыныннан аера алмый. "Приколлар банкы" билетлары кайбер терминалларның программаларына караганда, ешрак яңартылып тора. Һәрхәлдә, аларның дүрттән бере ялган кәгазьләрне рәхәтләнеп йотып тора. Мондый купюраларның чиксез саны аркасында Центробанк "Приколлар Банкы" белән даими көрәш алып бара, ләкин файдасыз. Акча сувенир продукциясе җитештерү һәм саклауга каршы җаваплылык кертү турында закон проекты да тәкъдим итеп карадылар, әмма моны артык чара дип санадылар һәм "фантик"ларга тимәделәр. Закон буенча алар ялган акча булып саналмый, чөнки анда "түләү чарасы булып саналмый" дип язылган.

Хәзер ялган акча һәр почмакта сатыла. Рәсми рәвештә, закон буенча. Җитештерүчеләр бастырып ята, сәүдәгәрләр сата, кулланучылар файдалана – һәркемнең бозыклыгы йә намусы кушканча...

Людмила САФИУЛЛИНА



Вячеслав ШИЛОВ



Валерий ТАРАСЕНКО





Дамир МОРТАЗИН

БУЛДЫРАЛМЫЙОВТАН БУЛДЫРГАНОВКА КҮЧҮ...

Рәссам Булдыралмыйовның фатирын талаганнар. Караклар икәү булган. Аларны очраклы рәвештә өйләреннән ерак түгел җирдә Булдыралмыйов үзе очраткан. Ашыга-ашыга ике ир-ат алагаем зур букчаларын шул тирәдә көтеп торган машинага төйиләр иде.

“Ял итәргә ашыгучылар, ахрысы, болар”, – дип көнләшебрәк уйлап куйды рәссам.

Каян белсен инде ул аларның үз өеннән шундый кыйммәтле әйберләрен ташыганын.

– Каракларның чырайларын хәтерегездә калдыргансыздыр бәлки – рәссамнар бит алар бу нәрсәгә бик оста, – диделәр аңа бу эшне тикшерүче полиция хезмәткәрләре, Булдыралмыйов аларга гариза язып килгәч. – Кыен эш булмас, портретларын ясап бирсәгез...

– Юк, әлбәттә, – дип ышандырып әйтте Булдыралмыйов.

Икенче көнне үк ул полиция бүлегенә “ял итәргә баручыларның” ике портретын ясап китерде.

– Аңламадым... – диде аптырап тикшерүче, рәссамның алып килгәннәренә озак кына карап. – Монда бит ниндидер квадратлар, почмаклар, түгәрәкләр...

– Мин шулай күрәм! Бу минем иҗади ысулым һәм сәнгати күзаллавым...

– Анысы шулайдыр... Ләкин сезне кыерсыткан әлеге җаннарны үзләренә охшатып ясарга кирәк иде бит, болай итеп түгел... – тикшерүче рәсемнәрне Булдыралмыйовның алдына этеп куйды.

Рәссам атна буе мастерскоеннан чыкмыйча ясый, ерта-ерта озак тырышты...

Ниһаять атна ахырында тикшерүченең өстәленә яңа портретлар ятты.

– Тере кебек күренәләр! – дип очынып куйды теге. – Болар бит безнең элеккеге танышларыбыз – Кысык белән Кимерчәк! Әле генә иреккә чыккан иделәр, яңадан иске гадәтләренә керешкәннәр! Тотабыз, ябабыз. Ә сезгә ярдәмегез өчен зур рәхмәт. Чүтеки сәнгать – бөек нәрсә!

Озакламый Булдыралмыйовка урланган бөтен әберләрен кайтарып бирделәр. Ярты елдан соң аның шәхси күргәзмәсе ачылды. Сәнгатенә мөкиббәннәр Булдыралмыйовта яңалык күреп шаккаттылар – монда инде квадратлар, почмаклар, түгәрәкләр юк иде. Күргәзмә залында еш кына: “Булдырганов!” дигән тантаналы яңгырашлар кабатланып торды. Бик күркәм урында “Җинаять һәм җәза” дигән триптих эленгән иде. Беренче полотнода рәссам Кысык белән Кимерчәкне чукмар тоттырып сурәтләгән, икенчесендә – үзен һәм тикшерүчене, өченчесендә Кысык, Кимерчәк артык ерак булмаган җиргә озатыла торган күренеш...

Күргәзмә зур уңыш казанды. Тамашачылар һәм тәнкыйтьчеләр рәссамның үз иҗатындагы яңа этап ачылышын бик югары бәяләделәр.

Яңа елмаюлар

ИШӘК НИЧЕК ЙӨРИ?

Затлы аргамакка атланган морза юлда ишәккә атланып барган картны очраткан.

– Ишәк ничек йөри? – дип сораган морза.

Карт, уйлап тормыйча гына:

– Ат өстендә, – дип җавап биргән.

КЕМГӘ НИЧЕК

Бай һәм укымышлы кешедән сораганнар:

– Сез менә төрле акыллы китаплар укыгансыз, киңәш итегезче, кайсы вакытта ашау яхшырак? Табиблар, профессорлар бу турыда нәрсә уйлый?

– Мин моны бернинди профессорларсыз әйтә алам. Бай кешегә теләгән чагында ашарга кирәк, ә ярлыга – кесәсендә акча булганда.

ТУРЫ ТЕЛЛЕ АХИРӘТ

Байның хатыны авырып киткәч, ахирәте аның хәлен белергә килгән.

– Кай төшең авырта, җаным? – дип сораган ул.

– Ямьсез урыныма сызлавык чыкты, – дип зарланган бай хатыны.

– Йөзеңдә андый нәрсә күрмим! – дип гаҗәпләнгән ахирәте.

ТАТЛЫ ТЕЛЛЕ ЯЛАГАЙ

Берзаман бай хезмәтчеләрен җыйган һәм аларга мондый сорау биргән:

– Әйтегезче, нигә минем корсагым шундый зур икән?

Хезмәтчеләр баш вата башлаганнар: бәлки тумыштандыр, ә бәлки берәр авырудандыр... Җавапларның берсе дә байга охшамаган.

Алар арасында бер ялагай булган. Ул болай дигән:

– Бай әфәнде, сезнең акылыгыз бик күп бит. Вакыт узу белән, ул башка сыймый башлый һәм корсакка шуып төшә. Ул шуңа зурая да инде.

БӘХЕТКӘ ЧЫДЫЙ АЛМАГАН


Бер егет өйләнгән. Яшь килен бераз яшәгән дә качып киткән. Яшь ирдән сорыйлар икән:

– Хатының нигә китте соң?

– Бәхетле тормышка түзә алмады. Таңнан торып сыер саварга кирәк түгел, малларны көтүгә куасы юк, тавыкларга җим бирәсе юк... Казан янында тирләп-пешеп ашарга әзерләргә дә кирәкми – рәхәтләнеп яшә генә. Бәхеткә чыдый алмады хатын.

Өенә барып карасалар – ихатасы бупбуш, ә үзе фәкыйрь икән.

Виктор ФЁДОРОВ




Валерий ТАРАСЕНКО



Вячеслав ШИЛОВ



Максим СМАГИН







ҖИР АСТЫННАН ХӘЗИНӘ

Казанда «Метроэлектротранс» предприятиесенең ике хезмәткәре хөкем ителгән. Баш инженер һәм җир өсте транспорты буенча энергетика хезмәте башлыгы буш вакытларында криптовалюта табу белән шөгыльләнү өчен үз предприятиеләреннән... электр энергиясе урлаганнар. Бу эшне башкару өчен энергия күп китә, шуңа күрә җиһазларын алар оешмаларының трансформатор подстанциясендә урнаштырганнар. "Бизнесменнар" өч айдан эләккәннәр. Хәтта шушы кыска вакыт эчендә генә алар метро хуҗалыгына 600 мең сум зыян китерергә өлгергәннәр. "Майнер"ларның күпме биоткин эшләгәннәре билгеле түгел, ә тиеш срокны суд билгеләячәк.

ЧӘЧӘК БҮЛӘК ИТӘМ...

Чистайда яшәүче берәү, сайт аша букетка заказ биргән чакта, программадагы бәяләрне үзгәртү җаен тапкан. Мәсәлән, 40 мең сум торган чәчәк бәйләме өчен 5 сум гына түләргә була икән. Саклык һәм тыйнаклык турында онытып, егет бөтенләй башын югалткан. Кыска гына вакыт эчендә сайт аша һәрберсе өчен 3-5 сум түләп, ул 79 букет сатып алган. Чәчәкләрне ул әнисенә, туганнарына, дусларына бүләк иткән, ә кайберләрен саткан. Үткен егетнең эшчәнлеге аркасында сайт хуҗасы өч миллион сум югалткан.

ЯЛГАН МӘХӘББӘТ

Бер Чаллы егете танышулар сайтында бәхетен сынап карамакчы булган. Берникадәр вакыттан аңа бер кыз исеменнән ялгыз бай ханымнарның күңелен күрергә чакыру килгән – түләү өчен, әлбәттә. Сөю хезмәте күрсәтүчеләр җәмгыятенә әгъза булып кергән өчен яшь иргә 12 мең сум түләргә туры килгән. Чираттагы түләү беренче күрешү өчен затлы бүлмә алып торырга киткән. Бары тик татлы күрешү барып чыкмагач кына, түләүле мәхәббәт әһеле алданганын аңлап, полициягә юл тоткан.

КЫЙММӘТЛЕ ВАКАНСИЯ

Түбән Камада яшәүче ир кеше эш эзләү сайтында үзенә туры килгән машина йөртүче урыны тапкан. Телефоннан эш бирүче белән очрашу турында сөйләшенгән. Аңа офисның адресын җибәргәннәр, һәм юлда сок һәм сигарет сатып алуын үтенгәннәр. Тиешле урынга барган арада, булачак машина йөртүчегә тагын шалтыратканнар һәм берничә мобиль телефонга, чекларын үзендә калдырып, акча салырга кушканнар. Ир кеше эш бирүчегә барлыгы 27 мең сум күчергән. Ә сөйләшенгән урынга барып җиткәч, анда бернинди дә офис тапмаган.

Рөстәм ЗАРИПОВ

Тукай туган көнендәге митингта каләмдәшләр тарафыннан әйтәсе килеп әйтелгән өндәмәләр:

• Ахмаклыкны "уянмаганлык" белән каплыйк!

Татфакны татар Гарварды дип атыйк!

• Әдәби кишәрлекләрне "буразна бозмаучылар"дан сөрдерик,

Барлыгыбызны, кемлегебезне дөньяга белдерик!

• Җырларларыбызны "сагыш", "язмыш", "ялгыш" сүзләре белән чуклыйк.

Китапларыбыз кибетләрдә сатылмаса, китапханәләрдә туплыйк!

• Шулар "укыла", дип, югарыга хисап язсын!

Нәтиҗәдә, премия, исем, титул бертуктаусыз яусын!

• Яуганннарны соскылы көрәк белән көрик,

300 әдип күтәрә алмаган темаларны ялгызы ачкан Гүзәл Яхинага өрик!


• Асрамадагы басмаларда калын-калын роман-эпопеялар чыгарып ятыйк!

Бөеклек турында хыялларыбызның чынга ашуын татыйк!

• Иҗат утында дөрләп яныйк!

Гыйбрәт өчен, гөрләп, тарихка кереп калыйк!..





Игорь КИЙКО

Валерий ТАРАСЕНКО



Виктор ФЁДОРОВ



Виктор БОГОРАД





• • •

Әгәр розеткадагы тишекләр зуррак, ә бармаклар нечкәрәк булса, шул чагында җүләрләр азрак булыр иде...

• • •

Бездә бит болай... Бер яктан карасаң – чын патриот инде менә. Ә икенче яктан ныгытып карасаң, аның йә чит илдә счёты бар, йә балалары урнашкан, йә булмаса шактый уңайлы йорты яки барысы да бергә шунда.

• • •

Карга биек чыршы очында утыра. Янәшәдән куян чабып үтеп бара:

– Карга, нишләп утырасың анда?

– Берни дә эшләмим.

– Мөмкинме миңа да бернәрсә эшләми утырырга?

– Әлбәттә.

Куян, тәпиләрен кушырып, куак астына кереп утырган. Янынннан төлке үтеп бара икән. Куянны күргән дә, ашаган.

Карга: "Карале, әйтәсе калган икән куянга, бернәрсә дә эшләмәс өчен, югарыда утырырга кирәк дип..."

• • •

– Койка (холодец) ашыйсыңмы?

– Юк, кичә ашаган идем инде!

– Ә аш?

– Аш булса, ашыйм.

– Ярый алайса, – дигән дә хатыны, койканы микроволновкага куйган.

• • •

– Нинди тәртипсезлек бу? Тагын йоклап ятасыз! Беренче көннән башлап эштән азат ителәсез.

– Беренче көннән генә бит әле ул. Ә хәзер ни өчен уятасыз?

• • •

Барысы да пенсиягә кадәр яшәргә хыяллана. Эшләүчеләре – гомумән, пенсиягә хәтле, пенсиядәгеләре – чираттагысын көтеп...

• • •

Табигать кешеләрнең җитешмәгән якларын төзәтергә тырыша. Сукырларның шәп ишетү сәләтен, саңгырауларның – яхшы күрү мөмкинлеген, ә башсызларга теләсә нинди темага уйлану, фикерләү сәләте бирә.

• • •

Ипотека аласың килсә, хезмәт хакың аз булып чыга! Ә балаларга түләүләр рәсмиләштерергә теләсәң, керемең артык!

БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Безне битлекләделәр дә – хәзер инде кешеләрнең чын йөзе югалып бара бугай.

Алмаз Хәмзин: Әмма хакимиятнең чын йөзе һаман саен ныграк ачыла бара...

Р. Н.: Әгәр РФ президентына бәя бирергә теләүчеләр табыла икән, алар аны артык агартырга да, артык каралтырга да тиеш түгелләр...

А. Х.: Аныкын бәяләп тормасаң да билгеле бит инде...

Р. Н.: Карьераң булмаса, "Кар ера" алмыйсың!

А. Н.: Юньле максатың булмаса, «мәк сат»арсың!..

Р. Н.: Күреп исем китте – бокста... атлеттан да "котлет" ясаучылар бар икән бит!

А. Х.: Ә сәясәттә тагын да көчлерәк ысул бар – гади халыктан хәерче ясау.

Р. Н.: Әгәр дә чалбарның кесәсе булмаса, ул сукыр бер тиенгә дә ярамас иде.

А. Х.: Төймәсе булмаса, диген...

Р. Н.: Себер карын күрмәгән африканнар Россия дигән илне аңлый алырлар микән?

А. Х.: Алар әле карсыз да аны аңламыйлар.

Р. Н.: Язмыш... дип аклану бигүк дөрес түгелдер, асылда Кеше үзен-үзе "ясый"...

А. Х.: Бигүк ясап бетереп булмый шул әле, комачаулаучылар күп...

Р. Н.: Кайсыдыр районда бер әтәч алтын йомырка салган, дип сөйлиләр. Дөрес микән бу?

А. Х.: Минем дә ишеткән бар. Кайсыдыр главаның малае турында сүз барадыр...

Р. Н.: Дошманыңа аткан таш, бумеранг булып, үзеңә әйләнеп кайтасылар бер дә ерак йөрми.

А. Х.: Әйе шул. Миндә күп алар.

Р. Н.: Зур акылга ия кешегә, аның белән идарә итү өчен, тагын да зуррак акыл кирәк!

А. Х.: Бу фикерең өчен рәхмәт сиңа, Рашат!

Р. Н.: Минемчә, маймыл кешедән килеп чыккан. Тәмәке тарту, аракы эчү кебек зарарлы гамәлләрдән читләшү өчен, алар йә урманга, йә Африкага качып беткәннәр...

А. Х.: Маймыл акыллары бар үзеңдә, Рашат дус, ләкин үзең шунда бер дә качмыйсың...

Р. Н.: Сәрхушнең сүзләреннән дә исерек фәлсәфә аңкый.

А. Х.: Монысына җавап бирмәү кулаерак булыр... Үпкәләмә!..

Николай ВОРОНЦОВ



Рөстәм ЗАРИПОВ

• • •

Яшиләр гел бергә, күзгә-күз, йөзгә-йөз,
Алар гүя игез, үлчәмнәре тигез.
Тайпылыш юк уңга, тайпылыш юк сулга,
Еллар уза, алар шул халәткә түзә...
Ничек шулай мөмкин? Ярый, серне чишәм,
Бу язмышка дучар идән белән түшәм...

• • •

Бездә һәр тармакны чуртан сөйри,
Тырышы аккошы, кысласы...
Омтылабыз якты киләчәккә, –
Алга китеп булмый, кыскасы...

Василий АЛЕКСАНДРОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Анатолий НЫРОВ



ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ



Максим СМАГИН



Сергей ЕРМИЛОВ



Алмаз ХӘМЗИН

АПТЫРАМА!..

Галиулла абзый капка төбендә...
Йөри нидер уйлап, тыз да быз.
Әйтә:
– Олигархларны талаганнар!
Җавабымда димен аңа болай дип:
– Аптырама, тыныч йоклыйбыз!

Нәсимәттинең дә йөзе борчулы...
Пугачёва киткән – нишлибез?
Әйтә:
– Галкинын да калдырмаган ич!..
Җавабымда димен аңа болай дип:
– Бетерешмә, тыныч йоклыйбыз!

Зәйнәп апа көн-төн гел бакчада,
Без дә төнлә бакча казыйбыз...
Әйтә:
– Кирәк, ди, ашарга бәрәңге!
Җавабымда димен аңа болай дип:
– Яшәсен маймыллар сыебыз.

Зиннәт бабай бүлнис юлын таптый,
Пенсиясе аз, йөри тешсез.
Әйтә:
– Аңкау сызлый теш булмагач.
Җавабымда димен аңа болай дип:
– Чыда, Җәннәттә күрешербез!

Абау!

ИСКИТКЕЧ МЕТРЛАР

Коми Республикасының Княжпогот районында шәхси йортларның берсендә яшәүче бер ханым үзе белән килешүдән туйган. Бөтен эш шунда: аның йорты документларда бер бүлмәле фатир буларак күрсәтелгән. Димәк, ул биш катлы йортларда яшәүчеләр кебек үк хокуклары һәм бурычлары булган. Аңа, мәсәлән, йортның фасадын буяу өчен, бердәнбер милекче булуга карамастан, идарәче компаниягә сайларга, йортта яшәүчеләрнең гомуми җыелышын үткәрергә һәм беркетмәләр язарга туры килгән. Ахыр чиктә, бюрократик волокита аны торак статусын үзгәртер өчен, судка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр иткән.

ЯЛГАН ГАРАНТИЯЛӘР

Санкт-Петербургта яшәүче берәү эзотерик оешмадан «ялган саклау булдырган» өчен суд аркылы зур сумма ала алган. Ир психологка мөрәҗәгать иткән, әңгәмә барышында аның оккульт фәннәр белән шөгыльләнүе һәм аның проблемаларында психологиянең көчсез икәнлеге ачыкланган. Бөтен бәла-казаларны бетерү өчен 5 миллион сумга «саклагыч гөмбәз» сатып алырга кирәк булган, һәм пациент моны эшләгән. Оккультист, караклык турында эш кузгатканчы, ул тылсымлы гамәлләр көткән. Шунысы гаҗәп, ул түләнгән миллионнарны гына түгел, «алдакчы»дан аның акчасыннан файдаланган өчен 799 мең сум акча түләттерә алган.

МАХСУС САКЧЫЛЛЫК

Ерак Көнчыгыш буенча Урман хуҗалыгы департаментының баш дәүләт инспекторы законсыз рәвештә урман кискән. Урман яклаучылар кулыннан Завитин урманчылыгындагы карагачлы участоклар зыян күргән. Табылган материалдан инспектор киң колачлы төзелеш эшләрен җәелдергән: үзенең заимкасында күпер төзегән, ике йорт, гараж, мунча һәм сарайлар төзегән. Кисү урынында полицейскийлар канауга ташланган «аеруча саклана торган территория» билгесен тапканнар. Табигатькә килгән зыян ярты миллион сумга якын бәяләнгән.

ШИФАЛЫ СҮГЕНҮ

Немец психологлары, ниһаять, рус кешесенең сүгенү сүзләрен куллану шифалы көчкә ия булуын белгәннәрен ачыклаганнар. Экспериментлар барышында сүгенүчеләрнең авырту хисе кимүен, өстәвенә, допинг кебек сүгенүнең көчәюен исбатлауга ирешкәннәр. Конкрет сүзләр юк, барысы да индивидуаль рәвештә. Әмма иң нәтиҗәлесе булып үзеннән-үзе килеп чыккан сүзләр санала. Дөрес, бер нюанс бар. Гадәти тормышта аны сирәк кулланучыларда гына нәтиҗәсе яхшы, калган очракларда шифалы сүгенүләр ияләшүгә генә китерә.



Вячеслав ШИЛОВ



Виктор ФЁДОРОВ



Валентин ДРУЖИНИН

Николай ВОРОНЦОВ



Виктор ВЕСЕЛОВ

Шалтырату

Телефон шалтырады. Людмила трубканы алды. Таныш булмаган ир-ат тавышы хәбәр итте:

– Ирегез җәяүле кешене бәреп киткән. Светофор янында, «зебра»да. Инспекторлар артыннан куып көчкә туктатканнар. Җиде елга кадәр утырачак. Әгәр эш судка барып җитсә. Ләкин хәлне әле үзгәртергә мөмкинлек бар...

– Ничек? – дип гаҗәпләнде Людмила.

– Мин ярдәм итә алам. Барлыгы илле мең сумга төшәчәк. Инспекторлар белән сөйләшеп куйдым инде. Алар каршы түгел. Хәзер мин сезгә барысын да аңлатачакмын...

– Мөмкин булса, аңлатыгыз инде, – диде Людмила еламсырап. – Ничек...

– Ничек акчаны миңа тапшырыгамы? – дип шатланды трубкадагы тавыш.

– Юк. Аңлатыгыз, ничек минем иремнең кеше бәрдерүе мөмкин, аның машинасы да юк бит?!

– Анысын белмим... – диде югалып калган ир. – Бәлки, дусларының берәрсе йөрергә биреп торгандыр? Үз машинасын.

– Аңа йөреп торырга?! – дип, тагын бер кат гаҗәпләнде Людмила. – Аның дусларыннан берәү дә аңа ышанып шешә тотып торырга да бирә алмый! Ә сез машина, дисез...

– Машинасы бармы, юкмы – аерма юк. Бәрдергән – димәк, утырачак! Күрәм, аңа ярдәм итәргә теләмисез.

– Күрәсез икән – бик шәп. Ә ул – юк! Аның күзләре – минус егерме. Ул машина йөртә дә белми. Аның правасы да юк.

– Димәк, мин ялгышканмын...

– Менә бит, бөтенесе дә ачыкланды! – дип шатланды Людмила.

Ир кеше дә шатланды:

– Нинди җиде ел ди ул?! Унга утырачак! Йә унбишкә! Сукыр һәм правасыз булуы җитмәгән, өстәвенә, йөртә дә белми! Сез иregezne бөтенләй яратмыйсыз бугай!

– Нигә яратмыйм? Нигә алай дип уйлыйсыз?

– Нигәме? Акча жәллисез! Ниндидер илле мең бит. Ә мин чын күңелемнән сезгә ярдәм итәргә теләгән идем...

– Минем өчен зур акча бу!

– Көлдермәгез! Кайда да булса эшлисездер бит?

– Әлбәттә.

– Илле мең дә җыя алмаслык хезмәт хакын кайда түлиләр икән?

– Кайда дип... Полициядә. Шунда эшлим. Өлкән тикшерүче булып. Алдап акча алучылар, жуликлар белән шөгыльләнәм. Ә сез, әйтергә кирәк, өй телефоныгыздан шалтыратып зур ялгыш ясадыгыз. Сөйләшүебезне мин язып алдым. Адресыгызны да ачыкладым. Кәкре тыкрык, 5 нче йорт, 12 нче фатир. Василий Иваныч! Әйдәгез, хәзер мин сезгә киләм, һәм сез бәйнә-бәйнә минем иремә ничек ярдәм итәргә теләгәнегезне сөйләрсез...

– Юк-юк!!! Мин үзем киләм. Адресыгызны әйтегез. Сөекле полициямә ярдәм йөзеннән үз теләгем белән акчалата бүләк ясарга телим...

– Бик яхшы! Килегез! Дәүләт хезмәтендәге кешегә ришвәт бирү итеп теркәп куярбыз...



«Чаян» оештырылганда аның алдына куелган максатларның берсе – инде егерменче еллар башында ук совет учреждениеләрен баса башлаган бюрократизм иде. Тиздән журнал битләрендә волокита, игътибарсызлык, кирәкмәгән белешмәләр алу өчен сәгатьләр буе чират торулар турында карикатуралар һәм фельетоннар барлыкка килде. Ул чакта бюрократизмны бер атака белән җиңеп булмады, һәм тәкәббер бюрократлар «Чаян» битләрендә озак елларга калды. Хәтта хәзерге компьютер заманында да ул чиновник-бюрократлар юкка чыкмады.

Ерак 1961 елда «Чаян» рәссамнары аларны менә ничек күргән.

И. БОБРОВИЦКИЙ



И. ХАНТЕМИРОВ



– Автографлар җыясызмы?
– Юк, гариза әзерлим!

В. ИГНАТЬЕВ



– Сүзе булмасын өчен, докладчыга алты сәгать бирергә дигән тәкъдим бар!

И. ХАНТЕМИРОВ



– Иптәш управдом, түшәмнән ага бит!
– Тынычланыгыз! Авария комиссиясе сезнең шикаятегезне тикшерәчәк!

Б. СТАРЧИКОВ

Бюрократның Яңа елы



– Кем син? Фамилияң ничек? Туган елың?

В. ИГНАТЬЕВ



– Тәнкыйтьләгез, иптәшләр! Тәнкыйть БЕЗГӘ СЕЗНЕҢ җитешсезлекләрегезне төзәтергә ярдәм итә.



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Хәзерге заман ирләре әллә ничегрәк?.. Шундыйларның берсе телефоны аша хатыныннан нindiерәк алма аласын сорап тора. Чын ир бит инде беркемнән дә нинди алма сайлыйсын сорап тормаячак. Үзенә кайсысы ошый шуны ала да вәссәлам. Хәтта ул бәрәңге булса да.

• • •

Рус теле өйрәнү өчен бик авыр, кайбер республикаларның мәктәп укучылары 100 балл җыйсалар да, июньдә рус теленнән, сентябрьдә Мәскәү югары уку йортларына килгәч, инде язу яки укыганда “чыктым аркылы күпер” диебрәк сөйләшәләр...

• • •

Хәзерге заман фермеры булу әйбәт: соя утыртсаң маен да, итен дә, колбасасын да сосискасын да, тавык итеннән ясалган котлетларын да, сөтен дә, шоколадын да, конфетын да, пилмәнен дә, сырын да аласың. Барысын да бер кырдан.

• • •

Кая ул чапкан җирдән атны туктату... Мегаполисларда шундый хатыннар бар – рульне йомшак кына борып алалар да, йөзәрләгән автомобильләрне туктаталар хәтта.

• • •

– Алло! Бу салым оешмасымы? Ни өчен миңа җир өчен алагаем салым чутлагансыз?
– Җир сүзе зур хәрефтән язылганмы әллә кечкенәдәнме?

• • •

Түрәләрне илебездә чыга торган машиналарга күчереп утырту идеясенә хәзер чын мөмкинчелек туды.

• • •

Белмим, пирожкилар нәрсә белән пешкән булгандыр, әмма Кызыл Калфак белән Бүре бер-берсе белән бик яхшы аңлашканнар.

• • •

– Сезнең клиникада түләүле хезмәт күрсәтәләрме?
– Әйе. Дәвалыйбыз бушлай, терелтәбез акчага.


• • •

– Чибәркәй, сезне озатырга мөмкинме?
– ЗАГСка кадәр генә.
– Юк, бу бик ерак.

Максим СМАГИН



Вячеслав ШИЛОВ





БАТКАКЛЫК

Хөрмәтле Чаян! Безнең телебез – рус һәм татарныкы чамадан тыш нык инглиздер-чурттыр телләр белән бик нык чупләнгән һәм буталган хәзер. Ә менә аның төрле элемтә кулланышындагы чагылышы ушны алырлык. Хәзер шуның мисалларын, кыскача рәвештә күзаллау өчен, кайбер өзекләр китерәм.

"Татарстанның Минмолы инвайтит бишенче яшь креаторларының митинг-поинтын. Бу вакыйга "Безнең заман" коллавында фест буларак үткәрелә. Ивентның программасы: семинар-тренинг, ворк-шоп арт-индустрия гурусыннан, эшлекле һәм мәдәниятле кейслар, экспертлар белән тәҗрибә уртаклашу. Бонуслар: free катнашу, фуд һәм коливинг, шәп вайб, апнутый скиллалар турында сертификатлар. Регистрациягә терим линк".

Менә шундый мәгълүмат, бик үк "ычкынган" кеше булмасам да, үзем дә аңлап бетермәдем. Яшьләрнең кыланып сөйләшү алымнарын куллансаң да тәрҗемә кылып булмаячак бит моны. Креатив булырга уйлаганнардыр, чынлыкта ниндидер кыргый француз катыш сүз боткасы, дөресрәге, хәреф боламыгы килеп чыккан. Бәлки берәрегез әлеге җөмләләргә мәгънә сала белер...

Г. ВАХИТОВ

ТҮБӘН КАМА

ТУЗГАН МИРАС

Кадерле "Чаян"! Быелгы ел Россия халыкларының мәдәни мирасы елы итеп игълан ителгән. Шул сәбәпле, Мәдәният йортларында халык гореф-гадәтләрен саклау ниятеннән төрле чаралар үткәрелә. Ә менә без, Уразлы авылында яшәүчеләр, мирас итеп гореф-гадәтләр генә түгел, авыл уртасына һәм мәдәният йортына, мемориалга илтә торган җимерек күпердән йөрергә тиеш. Кечкенә елга аша салынган бу күпергә бер генә дистә ел түгел инде. Аның инде тотынып чыга торган терәкләре, черегән бүрәнәләренә карарлык та түгел. Клубка культуралы чара карарга бару да – куркыныч гамәл.

Быел Җиңү көнендә мемориалга чәчәк салу өчен күперне бераз рәткә кертү өчен үзебезгә көч түгәргә туры килде. Такталарын, бүрәнәләрен алмаштырдык. Аллам сакласын, йә берәрсе егылып имгәнер. Хәзер без кайчан күперләр елын игълан итүләрен көтәбез, бәлки шунда төзәтерләр?!

Уразлы авылында яшәүчеләр

ЯШЕЛ ҮЗӘН


КАЗАН УТЛАРЫ



РӨСТӘМ ГАЛИУЛЛИНГА

(баш редактор)


Рөстәмдә бар галилек,
Рөстәмдә күп гадилек,
Рөстәмдәге нык булганлык –
Әдәбиятны зурларлык!



ВАКЫЙФ НУРИЕВКӘ

(урынбасар)

Вакыйф Нуриев журналда
Ун еллапмы утырды?..
Проза язудан тукталып,
Җыр язарга тотынды.



РАФИС КОРБАНГА

(проза мөхәррире)

Рафис Корбан әйтсә әйтә,
Чыдап кына торыгыз!
Язган-баскан әсәрләрен
Рәхәтләнеп укыгыз!



КАМИЛ КӘРИМОВКА

(прозаик)

Камил Кәрим көне-төне
Яза калын романнар.
Ул язганча бара төсле
Бу хәзерге заманнар...







ЛАНДЫШКА

(җаваплы сәркатип)

Ландыш булып, бүлмә бизәп,
Вазаларда гына торса да
Ярый бит инде югыйсә.
Ә ул җавап тота, әгәр
берәрсеннән
начар фикерләр килсә...

ФӘНИЛ ГЫЙЛӘҖЕВКА

(шигърият бүлеге)

Остарды егет язарга,
Шаяртырга өйрәнде.
Хәзер инде яза-яза
Сатирикка әйләнде.

ЛИЛИЯГӘ

(редактор-корректор)

Чәчәк кенә түгел шул ул,
Аның исеме шундый!
Җисеме асыл, үзе – гөл,
Эше журналда шаулый!







ЭЛЕОНОРАГА

(журнал туплаучы)

Элеонора, Элеонора –
“Казан утлары” нуры!
Журналыбыз битләренең
Яктысы, моңы, җыры!

ГӨЛИЯГӘ

(офис-менеджер)

Эзләп йөреп арып бетсәң,
Тапмасаң Гөлияне,
Шакы шунда бер белмәгән
Төрле-төрле бүлмәне.
Документка чумган булыр
Ул – матур кыз, күр әле!

ЛӘЙСӘНГӘ

(сайт мөхәррире)

Аның эше бик тә тыгыз –
Гел тутыруда сайт.
Юк-бар белән борчымагыз,
Китә-бара – офсайт.



АЛИНӘГӘ

(иҗтимагый челтәр)

Халык белән элемтәле
Челтәр корган Алинә.
Сихри сүзләр ятьмәсендә
Журнал даны беленә...



НАИЛГӘ

(машина йөртүче)

Көн дә дими, төн дә дими,
Чаба Наил ил буйлап.
Милләткә ул рух тарата
Туган тел хәлен уйлап.

Журналның юбилее уңаеннан эпиграммаларны Алмаз ХӘМЗИН әзерләде.

Рашат НИЗАМИ

Туган телем – дәрья...

Туган телебез – дәрья дигән бик зур байлыгыбыз, үлемсез хәзинәбез бар безнең! Моның шулай икәнлеген тарихи фактлар, эзләнүләр белән бик ансат һәм төпле итеп раслап була.

Мисаллар кирәкме? Рәхим итегез...

Гадәттә, бөек ачыш – шахматны Һиндстанда уйлап тапканнар, дип әйтелә. Пүчтәк! Борынгы дәүләтебезнең атаклы бер патшасы Фирзә атлы булган. Менә шуның хөрмәтенә – шахмат тактасындагы иң көчле фигураны ферзь дип атаганнар. Безнең бик популяр композитор һәм җырчыбыз Фирзәр Мортазин үз исеменең ерак гасырлар төпкеленнән килеп чыгышын белсә, үзенең концертларында әнә шул хакта сөйләп, тамашачыны тәмам уч төбендә биетер иде, валлаһи!..

Якташым, күренекле галим Әбрар ага Кәримуллин төрки-татар кавемнәре атаклы бозлык чорында Камчаткадан Америка кыйтгасына күченеп утырганнар дигән фәнни гипотезаны алга сөрде. Индеец-аборигеннарның бүгенге сөйләм теле әнә шуны раслый дип ачыш ясады.

Бу җәһәттән, җәмәгать, мин үзем дә бер деталь өсти алам, валлаһидыр. АКШта Оклахома дигән штат бар бит әле. Моның килеп чыгуы, шулай аталышы бик гади: кайчандыр бу төбәктә нәкъ менә Әкълимә дигән патшабикә идарә иткән. Европадан килгән баскынчылар аннары үзләренең тел-лөгате ягына аударып, аны Оклахома (Әкълимә ханым) дип йөртә башлаганнар. Ә инде "Камчатка" атамасының Камчат бүрек дигәннән алынуын сөйләп-аңлатып тору кирәк микән?

Инде бу тирәләрне урыйбыз икән, "Татар бугазы" дигән исемгә дә тукталмыйча ярамас. Ни өчен япун, монгол яисә башкорт бугазы түгел? То-то! Нәкъ менә безнең борынгы бабаларыбыз әлеге бугазны озак дәверләр үз кулында тотканнар.

Бервакыт, совет чорында, шагыйрь дустыбыз Разил Вәлиев шалтырата:

– Мин Кабулда хәзер. Мине әйбәт кабул иттеләр...

Бактың исә СССРның ул чактагы вәкалатле илчесе, Татарстан "обкомы"ның элекке беренче секретаре Фикрәт Табиев хозурына килеп төшкән икән бу. Шулай булгач, Кабул сүзенең каян килеп чыгышы хакында бәхәсләшеп тә торасы юк.

Берчакны шулай минем күз алдымда ике язучы дусларым бәхәсләшә-тарткалаша башладылар. Мәхмүт Хәсәнов белән Альберт Хәсәнов инде (хәзер мәрхүмнәр). Халхин-Гол сугышына барып төртелде болар. Ягъни Монголиядәге Хәсән Күле бабамныкы, минеке! – диләр. "Юк, минеке!" – дип, тәмам чәкәләшә болар, менәтерә...

Инде Һиндстанга барып егылыйк. Анда Әхмәтабад дигән кала бар. Шәһәргә бу исем минем хөрмәткә кушылган, дип әй өзгәләнер иде шагыйребез Әхмәт Рәшит.

Шәхсән, мин үзем дә "Рашат Мияссарович" дип эндәшсәләр, кайчакны – әтинең исеме Мисыр (мәссер) сүзеннән килеп чыкмады микән дип уйлана калам...

Россиягә хезмәт кылган тарихи исемнәрнең байтагы – безнеке. Әйтик, адмирал Нахимов – Нәгыйм улыннан алынган. Суворовның сувар нәселеннән булуы да мәгълүм ич, кардәшләрем. Кулына мылтык тотып Альп (тагын безнеке – Алып сүзеннән!) тауларын кичкәндә Суворовның үзенең солдатларына: "Бу – безнең соңгы шанс! (ышаныч) дип әйтүе дә тарихта теркәлеп калган.

Ну, бу татарны! Җир шарының байтак кыйтгаларын тетрәткән, исем-җисемнәрне ташка уйган!

Яңа исемнәр, атамаларны шәрехләүдә эшне туктатмасак иде...

Безнең туган телебез чишмәдәй челтери, карурмандай шаулый, болын чәчкәләре дә телебездә тирбәлә. Иншалла, алга таба да шулай булыр һәм булачактыр. Урысның "Ур-ра!" сүзе белән сүземне тәгәллим. Онытып бетермик: "Ур-ра!" сүзе дә татарның "Ура!" – ягъни урап ал дигән өндәмәсеннән алынган.

ТАТ МЕДИА

«БӘКЕР» ШИФАХАНӘСЕНӘ ИКЕ КЕШЕЛЕК ЮЛЛАМА

«ТАТМЕДИА» ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫНА ЯЗЫЛГАН ӨЧЕН ТЕЛЕВИЗОР, ЭЛЕКТР ИТТАРТКЫЧ, РОБОТ-ПЫЛЕСОС ҺӘМ БАШКА БҮЛӘКЛӘР ОТ

1 ЯЗЫЛ 2 ҖИБӘР 3 ОТ

Акциянең срогы 2022 елның 16 маеннан 2022 елның 20 сентябренә кадәр. Заявкалар 2022 елның 15 августына кадәр кабул ителә.
Оештыручы «ТАТМЕДИА» АҖ. Реклама 16+.
Товарлар рәсемдә тәкъдим ителгәннән аерылырга мөмкин.



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 6 (1919) июнь 2022

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.
420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 01.06.2022 ел.
Тираж – 2684 Заказ О-1517
Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле
16+

Уйна да, уйла да!

ШАГЫЙРӘ ЭЛЬМИРА ...
ЖИЛӘК-...
ЯЗУЧЫ ЮНЫС ...
ШАГЫЙРЬ ГАЗИНУР ...
АРТИСТ ... БАҺМАНОВ
"ЙӨРӘКТӘ ... ГЫНА"
ТЕЛЕ-ДИКТОР ... ЗАҺИ-ДУЛЛИНА
"БЕР ТАУДА ... ЧИШМӘ"
"... СУЛАР ГЕЛ ШУЛАЙ"
"КҮҢЕЛЕМДӘ ИКЕ ..."
"... ГЫНА, МОҢ ГЫНА ЖЫР АГА"
КАМА
ВЯТКА
... ТЕЛЛЕ, ҮТКЕН
«ЖИР ЖИЛӘГЕ ... БУЛА"
ХАЛЫК ЖЫРЫ
МУЗЫКАЛЬ ЖАНР
«БИК САГЫНДЫМ ... БУЙЛАРЫН»
КАТЫ СЫЗЫМ КӘГАЗЕ
ДОЛЛИ
ЯЗУЧЫ ... ИХСАНОВА
"..." АНСАМБЛЕ
КИНОАКТЁР БРЮС ...
...-ТУАР
КУХНЯ ИНСТРУ-МЕНТЫ
ТУПОЛЕВ САМОЛЁТЫ
НОТА
"КҮҢЕЛЛЕ ... ИТЕГЕЗ"
"... ЧУКЛАР, ДИМ-ДИМ"
... ЭТЕ
"АК БАРС ..."
ЗУР, БӨЕК
"... КАЕН"
ТУГАН ...
СЕБЕР УРМАНЫ
БАЙРАК
"НАРАСЫЙ ..."
... БИГИЕВ
"ЕРАК ХӘЗЕР ... ЛАР"
НУР ...
"..." КАРГА
"ТӘРӘЗӘМӘ ТӨШКӘН ... НУРЛАРЫ"
АНТОНОВ САМОЛЁТЫ
"(-1). ... УРМАН"

Ринат АБЗАЛОВ төзеде

ТАБЫШМАК ВӘ АЛЫШМАК

1. Нәрсә ул дипломатия?

2. Эленеп тора груша, ә ашап булмый. Нәрсә ул?

3. Кем ул психолог?

4. «Кайда туган, шунда кирәге чыккан» әйтемдә кем чагыла?

5. Нәрсә ул бал биюе?

6. Җәмәгатьчелек фикере нәрсәне аңлата?

7. Бакчага барабыз дип, балалар кайчан җайлырак уяна?

ҖАВАПЛАР

1. Юкны бар итеп: әнәсеннән җебенә кадәр сөйләп бирү. 2. Табышмак. 3. Үзеңнән зарланган өчен акча алучы. 4. Гинеколог. 5. Партнёрың аягыңа басканчы, үз аягыңны алып өлгерәсең. 6. Берәүдән дә сорамыйча, башкалардан тагылган фикер. 7. Ял көннәрендә.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 5 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«КИЧЕР КАЙТА АЛМАВЫМНЫ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы)
Б. ШАЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.),
С. ШАЙХУЛЛИН (Казан),

Җиңүчебез – Чаллыдан

Гали БАҺАВЕТДИНОВ!

Дан тавына сез менгәч — еламагыз, без көлгәч




Рәссам **Наил ГАЛИМОВның** исеме республикада гына түгел, аннан еракта да билгеле. Талантлы рәссам, график һәм реставратор буларак та беләләр аны. Ә менә Наилнең оригиналь шарж остасы булуын кайберәүләр белмидер дә. Татар эстрадасы артистларының шаян портретларыннан торган бүгенге сәхифәбезне күреп, укучыларыбыз моңа үзләре дә инаныр.



САЛАВАТ



Элвин ГРЕЙ



Гүзәл УРАЗОВА



Айдар ГАЛИМОВ

